**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

11.04.2018 348-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2016 елның 23 маендагы 450-п номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм Табигый ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2016 елның 23 маендагы 450-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының 2017 елның 01 мартындагы 246-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Әлеге Регламент гамәле радиоактив, биологик һәм медицина калдыклары белән эш итү мәсьәләләренә кагылмый»;

1.3 пунктның 1.3.5 пунктчасында икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.5. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 1.4, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – РФ СК) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1998, № 31, ст. 3824);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – № 89-ФЗ федераль закон), (Россия

Федерациясе Законнар җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирәлекне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектларны ачыклау критерийларын раслау турында» 2015 елның 28 августындагы 903 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 903 номерлы карары), (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 07.09.2015, № 36, 5043 ст.);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2010 елның 25 февралендәге 50 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 50 номерлы боерыгы белән расланган Тәртип) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2010, № 17, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты дәрәҗәсенә карап калдыкларны куркынычлылыкның I-V классларына кертү критерийларын раслау турында» 2014 елның 4 декабрендәге 536 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 536 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 31 декабрь);

Татарстан Республикасы Экология кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә), («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ

регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының «Шәхси эшкуарларның, юридик затларның (кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш) төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле объектларда аның процессында калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) башка төрле эшчәнлегенә карата калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 30 ноябрендәге 1368-п номерлы боерыгы (алга таба – РФ ЭТРМның 1368-п номерлы боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләр) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2016, 22 декабрь).»

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:
җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба – калдыклар) – җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү процессында яисә куллану процессында барлыкка килгән, юкка чыгарыла торган, юкка чыгару өчен билгеләнгән яисә әлеге федераль закон нигезендә юкка чыгарылырга тиешле матдәләр яки предметлар;

калдыклар белән эш итү – калдыкларны җыю, туплау, транспорт белән күчерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек;

калдыкларны урнаштыру – калдыкларны саклау һәм күмү;
калдыкларны саклау – калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, күмү максатларында унбер айдан күбрәк срокка махсуслаштырылган объектларга урнаштыру;

калдыкларны күмү – алга таба утильләштерелергә тиешле булмаган калдыкларны зарарлы матдәләрнең әйләнә-тирәлеккә эләгүен чикләү максатларында махсус саклау урыннарында изоляцияләү;

калдыкларны утильләштерү – калдыкларны товарлар (продукция) җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен файдалану, калдыкларны кабат куллануны да кертеп, шул исәптән калдыкларны турыдан-туры билгеләнеше буенча кабат куллану (рециклинг), аларны тиешле әзерлектән (регенерациядән) соң җитештерү циклына кайтару, шулай ук аларны кабат куллану өчен файдалы компонентларын алу (рекуперация);

калдыкларны зарарсызландыру – калдыкларның кеше сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирәлеккә булган тискәре йогынтысын киметү максатларында калдыкларның массасын киметү, аларның составын, физик һәм химик үзлекләрен (махсуслаштырылган җайланмаларда яндыруны һәм (яисә) йогышсызландыруны да кертеп) үзгәртү;

калдыкларны урнаштыру объектлары – махсус җиһазландырылган, калдыкларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын үз эченә ала торган корылмалар (полигон,

шлам саклана торган урын, шул исәптә шлам амбары, радиоактив, агулы һәм башка төрле иләк асты матдәләрен, тау токымнарын саклау урыннары һ.б.);

калдыклар урнаштыру лимиты – әлеге территориядә экологик вәзгыятьне исәпкә алып, калдыкларны урнаштыру объектларында билгеле бер срокка билгеле бер ысул белән урнаштырырга рөхсәт ителә торган конкрет төрдәге калдыкларның чик дәрәҗәдә мөмкин булган күләме;

калдыклар барлыкка килү нормативы – продукция берәмлеге җитештерелгәндә конкрет төрдәге калдыкларның билгеләнгән күләме;

калдыклар паспорты – калдыкларның тиешле төргә һәм куркынычлылык классы калдыкларына каравын таныклаучы, аларның составы турында белешмәләрне үз эченә ала торган документ;

калдыклар төре – калдыкларны классификацияләү системасы нигезендә уртак билгеләре булган калдыклар җыелмасы;

калдыкларны җыю – калдыкларны аларны эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыруны, урнаштыруны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында кабул итү;

калдыкларны транспорт белән күчерү – калдыкларны транспорт чарасы ярдәмендә юридик затның яисә шәхси эшкуарның мөлкәтендә торучы яисә аларга башка төрле хокукларда тапшырылган җир кишәрлеге чикләреннән читкә күчерү;

калдыкларны туплау – алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында унбер айдан артмаган срокка калдыкларны урнаштырып тору;

калдыкларны эшкәртү – сортларга аеруны, сүтүне, чистартуны да кертеп, калдыкларны алга таба утильләштерү өчен беренчел әзерләү.

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм тапшыру, мөрәҗәгать итүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә аңлашыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелде».

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктында уникенче абзацта «кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән» сүзләрен «почта юлламасы белән» сүзләренә алмаштырырга;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1. Шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтел-гән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләүгә дәүләт пошлинасы түләнмәү;<br>3. Мөрәҗәгать итүченең объекты федераль дәүләт экология күзәтчелегенә кертелүе;<br>4. Мөрәҗәгать итүченең материаллары составында ялган белешмәләр яисә төгәл булмаган мәгълүматлар булу, шул исәптән:<br>- мөрәҗәгать итүченең материаллары составында фальсификацияле документлар булуы ачыклану;<br>- калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектының ТР ЭТРМның 1368-п номерлы | 89-ФЗ номерлы федераль законның 11, 18 статьялары;<br>7-ФЗ номерлы федераль законның 19, 20, 22, 24 статьялары;<br>ТР Экология кодексының 21 статьясы;<br>РФ Хөкүмәтенең 903 номерлы карары;<br>ТР ЭТРМ 1368-п номерлы боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләр |

| | | |
|---|---|---|
| | боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләрдә билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектында мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны урнаштыруга лимитлар сорала торган калдыкларның составы, куркыныч үзлекләре, әйләнә-тирә мохит өчен куркынычлылык класслары турында белешмәләрнең булмавы ачыклану;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты составында китерелгән җитештерү калдыклары составы турындагы белешмәләр техник компетентлыгы расланган лабораторияләрдә билгеләнгән тәртиптә уздырылган аналитик тикшеренү нәтиҗәләре белән расланмау яисә мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты составында китерелгән куллану калдыклары составы турында белешмәләр документаль расланмау;<br>- калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты составында китерелгән калдыкларның составы һәм үзлекләре, аларның әйләнә-тирә мохит өчен куркынычлылык классы турында белешмәләрнең техник компетентлылыгы расланган аналитик лабораторияләрдә уздырылган аналитик тикшеренүләрнең нәтиҗәләренә | |

| | | |
|---|---|---|
| | туры килмәве, мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты составында китерелгән калдыкларның әйләнә-тирә мохит өчен куркынычлылык класслары турында белешмәләрнең билгеләнгән тәртиптә нигезләнмәве (РФ Табигать министрлыгының 536 номерлы боерыгы белән расланган криетрийларга туры китереп, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясау дәрәҗәсе буенча куркынычлылык-ның I-V классларына кертелүен нигезли торган материалларның булмавы);<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектында күрсәтелгән калдыкларның кодлары калдыкларның федераль классификация каталогында билгеләнгән калдыклар кодларына туры килмәве ачыклану;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектында күрсәтелгән калдыклар барлыкка килү нормативлары ТР ЭТРМның 1368-п номерлы боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләрдә билгеләнгән таләпләрне бозып билгеләнү;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектында күрсәтелгән калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы турында белешмәләрнең калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә фактик | |

| | | |
|---|---|---|
| | йогынтысының техник компетентлылыгы расланган лабораторияләрдә билгеләнгән тәртиптә уздырылган аналитик тикшеренүләр нәтиҗәсе белән расланган дәрәҗәгә туры килмәве ачыклану;<br>- мөрәҗәгать итүче тапшырган калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүче балансында торучы калдыкларны урнаштыру (саклау) объектларын урнаштыру һәм аларның сыйфатламалары турында белешмәләрнең әлеге объектларның фактик җиһазланышына һәм торышына туры килмәве ачыклану;<br>- мөрәҗәгать итүче балансында торучы калдыкларны урнаштыру (саклау) объектларының әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысының артып китүе ачыклану.<br>Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту нигезләре булып мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларда нинди дә булса белешмәләрнең булмавы яисә төгәл булмаган белешмәләр булуы тора.<br>Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары дубликатын бирүдән баш тарту нигезе булып үзе өчен калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары элегрәк билгеләнмәгән мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итүе тора. 89-ФЗ номерлы федераль законның 11, 18 | |

| | | |
|---|---|---|
| | статьялары;<br>7-ФЗ номерлы федераль законның 19, 20, 22, 24 статьялары;<br>ТР Экология кодексының 21 статьясы;<br>РФ Хөкүмәтенең 903 номерлы карары;<br>ТР ЭТРМ 1368-п номерлы боерыгы белән расланган Методик күрсәтмәләр | |

2.10 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләгән өчен 1600 сум күләмендә дәүләт пошлинасы алына»;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.13 пунктында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә»;

2.14 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте һаваны кондиционерлау системасы, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тудырыла (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

4 бүлекнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору түбәндәгеләрне үз эченә ала: мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләү, Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләү.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;
документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;
дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар башкарылуны тикшереп тору максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Министрлыкның, шулай ук аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең яисә хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт хезмәткәренең яисә хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү вакыты бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылу очрагында;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача формада яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан (https://uslugi.tatarstan.ru) файдаланып җибәрелә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте алучыларның шикаятендә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең яисә хезмәткәрнең исеме;

мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, аның вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең яисә хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең яисә хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.5. Министрлыкка яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына килгән шикаять шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат тарафыннан аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә, ә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны яки хаталарны төзәтүдән баш тартуына яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта, аны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә»;

түбәндәге эчтәлекле Кушымта (белешмә) өстәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, зарарсызландыру һәм урнаштыру турында хисаплылык (статистика хисаплылыгыннан кала) турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар Министрлыгы**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр – Шадриков Александр Валерьевич | (843)267-68-01<br>(843)267-68-02 | Aleksandr.Shadrikov@tatar.ru |
| Министрның әйләнә-тирәлекне саклау буенча беренче урынба-сары – Камалов Рөстәм Илдар улы | (843)267-68-19 | Rustem.Kamalov1@tatar.ru |
| Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынты-ны нормага салу идарәсе баш-лыгы – Шәһидуллина Рәисә | (843)267-68-90 | Raisa.Shagidullina@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Габдулла кызы | | |
| Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу бүлеге башлыгы – Богатырев Сергей Адольфович | (843)267-68-81<br>(843)267-68-49<br>(843)264-49-37 | Sergey.Bogatyrjov@tatar.ru |
| Документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге | (843)267-68-04<br>(843)267-68-05 | eco@tatar.ru. |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигый ресурслардан файдалану һәм әйләнә-тирәлекне саклау мәсьәләләре бүлеге башлыгы – Фәсхетдинов Марат Гайса улы | (843)264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В.Шадриков